УДК 821.51

***Н.Х. Суюнова***

# ИҢ ЯҢА НУГАЙ ӘДӘБИЯТЫНДА ТАРИХИ ЭССЕ
## (Иса Капаев прозасы материалында)

В статье представлено эссеистическое творчество современного ногайского писателя Исы Капаева (род. в 1949 г). Экскурс в историю жанра, а также анализ путей развития его в ногайской литературе XX века позволяет прийти к выводу об органичности этого жанра для ногайской художественной традиции. На примере прозы И. Капаева рубежа веков обосновывается востребованность и актуальность этого пограничного литературного жанра. Анализ целого ряда исторических эссе писателя демонстрирует перспективность и плодотворность обращенности художественного творчества к неканоническим жанровым формам.

**Ключевые слова:** традиция, многонациональная литература, эссе, пограничный жанр, реконструкция историко-культурной реальности.

The article presents the essay work of the modern Nogai writer Isa Kapaev (born in 1949). An excursion into the history of the genre, as well as an analysis of the ways of its development in the Nogai literature of the twentieth century, allows us to come to the conclusion that this genre is organic for the Nogai artistic tradition. By the example of I. Kapaev's prose at the turn of the century, the demand and relevance of this borderline literary genre is substantiated. An analysis of a number of historical essays by the writer demonstrates the promise and fruitfulness of the appeal of artistic creativity to non-canonical genre forms.

**Keywords:** tradition, multinational literature, essays, borderline genre, reconstruction of historical and cultural reality.

Иң яңа заманның күпжанрлы нугай әдәбияты – Россия Федерациясендә, аерым алганда, аның ике субъектында – Карачай-Черкас Республикасында (Кубань нугайларында) һәм Дагстан Республикасында (дала нугайларында) үсеш кичерүче нугай телле әдәбият. Гомумтөрки мәдәниятнең, Урта гасырлар нугай эпосының, йырау поэзиясенең гаҗәеп бай традицияләрен, күпмилләтле совет әдәбиятының мәгърифәтчелек чоры традицияләрен үзләштергән бу әдәбият хәзер сәнгатьлелекнең яңа формаларын эзли. Һәм бу яңа формалар үзенчәлекле традицияләр һәм әдәбиятара сәнгати тәҗрибәнең синтезыннан гыйбарәт.

Хәзерге заманда күренекле нугай язучысы, Төньяк Кавказ һәм Россия әдәбиятында, төрки дөньяда танылу алган әдип Иса Капаев (1949 елгы) прозасы бу тезисның дөреслеген тагын бер кат раслый. Ул бүген дә иҗади эзләнүләрен туктатмый. Һәм эшнең асылы бу очракта, әлбәттә, язучы эзләнүләр алып барган вакыт һәм киңлекнең (хронотоп) колачлы булуында. Рухи дөньяның тирән архаик катламнарына күмелү – мифоэпик универсалийләр язучыда тиз үзгәрүчән хәзерге дөнья чынбарлыгын ачык сәнгати бәяләү белән яраша.

Мондый зур вакыт аралыгында туктаусыз иҗади эзләнү белән шөгыльләнү сәләтенә ия булу, барыннан да элек, язучы шәхесенә игътибар бирүне сорый һәм аның тотрыксыз дифференциация билгеләренә ия канун саналмаган жанрларга чын күңелдән бирелгәнлеген аңлатып бирә. Аларга, барыннан да элек, сәнгати-публицистик формалы *эссе* кебек жанрны кертергә кирәк. Бигрәк тә тарихның борылыш мизгелләрендә, күз ачып йомганчы юкка чыккан чынбарлык күренешләренә оператив иҗади реакция ысулы буларак, нәкъ менә шундый универсаль, анык чикләре булмаган жанрдан файдалану «уңайлы».

Нугай әдәбиятында узган гасырның беренче яртысында ук эссе жанрының аерым билгеләре һәм үзенчәлекләре туплана башлый. Ул вакытта, гомумсовет мәдәни динамикасы агымында үскән яңа язулы әдәбият үзенең жанр арсеналын актив баета. Бу халыкның мәдәни «хәтере»ндә традицион фольклор-эпик традицияләр саклану аркасында мөмкин була. Аларда беренче нугай совет язучылары (Б. Абдуллин, Ф. Абдулҗәлилов, Х. Булатуков) иҗатында мөстәкыйль жанрлар буларак үсеш алган барлык жанр төрләренең яралгылары бар иде. Әлеге язучылар иҗатында акрынлап прозаның төрле дәрәҗәдә эссе билгеләренә ия сәнгати-публицистик жанрлары – очерк, новелла, фельетон, хикәя, повесть, роман формалаша.

XX гасыр уртасында «алтмышынчы еллар» язучылары һәм аларның 70 – 80 нче еллардагы дәвамчылары, шулай ук әдәбият белгечләре арасында бу жанр белән кызыксыну шактый көчәя, һәм моңа әдәби тормышның җанлануы, әдәби иҗатның индивидуальләшүе, әдәбият тудыруда һәм аны өйрәнүдә догматик принциплар һәм алымнар энтропиясе башлану, борынгы төрки рун язуы, Урта гасырлар нугай эпосы һәм *йырау* поэзиясе традицияләрен кертү хисабына язучылар иҗатының тарихи-мәдәни контекстын баету кебек «җепшеклек» чорында күзәтелгән күренеш һәм процесслар сәбәп була. Шулай итеп, әле жанр буларак формалашып җитмәгән эссе, төгәлрәге, аның билгеләре прозаикларның очеркларында, публицистик мәкаләләрдә, эпистоляр мираста, «җепшеклек» чоры нугай шагыйре Гамзат Аджигельдиев (ул елларда Мәскәү М. Горький исем. Әдәбият институты студенты) лирикасында чагылыш таба. Аннан соң авторлык башлангычы ярылып яткан лирик-фәлсәфи этюдлар нугай шагыйрәләре Келдихан Кумратова, Кадрия Темирбулатова иҗатларында пәйда була. Эссе билгеләре иртәрәк иҗат ителгән әсәрләрдә дә (бераз гына) тоемлана: Фазыйл Әбделҗәлиловның сугыш турындагы прозасында («Атадынъ улы»), прозаиклар Суюн Капаевның («Эске уйдинъ сонъы», «Бекболат», «Тандыр», «Ювсан», «Ердинъ йылувы») Курупторсын Оразбаевның («Атадынъ кушагы») сугыштан соңгы төзелеш турындагы повесть һәм романнарының лирик-фәлсәфи чигенешләрендә. Бу әсәрләрдә патриотизм – кече һәм зур Ватанга кешеләрне бер-берсенә якынайтучы аерым хис белән карау автор һәм геройларның кичерешләрен аңлауда тирән психологизм чаралары белән чагылдырылган. Шул ук вакытта еш кына бәян ителгәннең ни-

гезендә – документаль таныкламалар, сурәтләү объектлары – сәнгати уйланылган, чынбарлыкның беллетристиклаштырылган вакыйгалары һәм реаль язмышлар ята.

Эссе, билгеле булганча, чиктәш жанр – Вакытка бәйлелек, бүгенге белән чагыштыру аңа публицистиклык төсмере бирә. Фәнгә (кагыйдә буларак, гуманитар фәннәргә) аны уртак фикер объекты, аналитик башлангыч якынайта. Эмоциональлек һәм образлылык – сәнгати иҗаттан. Әсәрдә ышандыру функциясе өстенлек итеп, теманың традицион трактовкасы белән бәхәскә кергән һәм күренешкә стереотип карашы булган авторның роле күбрәк аерымланган саен, классик эссе билгеләре, стиле ачыграк күренә.

Нугай әдәбиятында эссе XX гасыр ахырына жанр буларак оеша башлый (Елена Булатукова, «Айкан йоллар»). Әмма бары И. Капаевның XX–XXI гасырлар чиге прозасында гына бу жанрның формаль үзенчәлекләрен апробацияләү, эзлекле сынау процессы интенсив төс ала. И. Капаевның «Юк булучы күләгәләр» (1999), «Үлемсез дала» (2004), «Мойынтымар» («Мониста») (2009), «Ялын янлы Сарайшык» (2014), «Язмыш кылычы» (2017) китапларының эчтәлеген тәшкил иткән тарихи эссе милли әдәбият эстетикасын, шул исәптән, Урта гасырлар нугай тарихи-функциональ жанрларының, барыннан да элек *толгау* (тарихның хәлиткеч мизгелендә геройның фәлсәфи фикер-монологы) һәм *нарратив шәҗәрәнең* (хикәяләүгә корылган нәсел хроникалары), ыруглык үзенчәлекләрен актуальләштерү хисабына да шактый баета.

XX гасырда күпмилләтле совет әдәбиятының (нугай әдәбияты да шуның бер өлешен тәшкил итә) дөньякүләм мәдәни процесста катнашучылар белән үзара бәйләнешләрен ныгыту, иҗади аралашуның алгы планында – Әдәбият институты мохитендә, бөтенсоюз иҗат мәйданчыкларында И. Капаевның иҗат кешесе буларак формалашуы нәтиҗәсендә аның прозасында эссе М. Монтень «Тәҗрибәләр»е, немец романтикларының хезмәтләре туу чорыннан туплана килгән, рус классикларыннан А. Герцен, Ф. Достоевский, соңрак – Б. Пастернак, К. Паустовский, Р. Гамзатов, Ч. Айтматов, О. Сөләйманов әсәрләрендә һәм, әлбәттә, нугайларның «алтмышынчы елгылар» иҗатында дәвам иттерелгән Европа жанр оешу тәҗрибәсен дә үзләштерде.

И. Капаевның эссе жанрындагы беренче тәҗрибәләре – күп еллар дәвамында язылган лирик көндәлекләре, прозадагы фәлсәфи миниатюралары, соңыннан «Мойынтымар» («Мониста») җыентыгына кертелгән тәүбә-истигъфар этюдлары. Шунда ук иҗатының таңында туган автобиографик хикәяләре («Бирешмәде»), лирик повесте («Балачак яшеренгән Куржун»), замандашлары белән диалоглары («Сынтаслы хакында толгау»), «Вокзал», «Кобызшы» («Гармунчы»), тарихи *таварыхлар* (риваятьләр) катламын әдәби эшкәртү («Юкка чыгучы күләгәләр») һәм аннан соң, масштаблы гомумиләштерүләр аша, жанрның үзенә күчү – тарихи эсселар сериясен булдыру («Бөек

дала мародерлары», «Үлемсез дала», «Ялын янлы Сарайшык», «Язмыш кылычы»).

Аларда фән, публицистика һәм сәнгати иҗат чикләрендә нугайларның күпгасырлык тарихындагы хәлиткеч чорларда тарихи-мәдәни чынбарлыкның автор версиясе тәкъдим ителә, аерым тарихи шәхесләрнең роле ачыла, бу исә XX гасыр ахырында, массачыл аңны үзгәртеп кору елларында яңа ачылган фактлар аркасында – мөмкин булды. Бу замандагы хәрәкәтчән иҗтимагый процесслар, гасыр азагында фәнни һәм мәдәни киңлектә автор карашы аша уйланылган фактологик яңалыкларга тиз арада реакция ясау өчен иң нәтиҗәле ресурс буларак, эссены актуальләштерде. Әлеге һәм күләме, һәм әһәмияте буенча зур материал системалаштыруны, фәнни бәяләүне таләп итте. Фән дәлилләү базасын булдыру өчен кирәкле таныкламаларны туплаган арада, әдәбият инде гамәл кыла башлый ала. Гипотезалар тәкъдим итү, ерак үткәндәге тарихи вазгыять версияләрен конструкцияләү, вакыйгалар үсеше мантыйгын реконструкцияләүгә эссе жанрындагы прозаның көче җитәрлек була. Өстәвенә элек билгеле булмаган тарихи-мәдәни контекст фактларын халыкка мондый тиз җиткерү ысулы, аерым алганда, нугай җәмгыятендә башланган милли үзтәңгәлләшү процессын үстерү, үз-үзеңне танып белү өчен кирәк иде. Нигездә, зыялылар арасында эссе жанрына сорау зур булу шуның белән аңлатыла да. Мондый нарративлардагы аналитик, фикерләүгә корылган башлангыч уйлануларны киң җәелдерә, гуманитар, иң беренче чиратта тарихи фән үсешенә этәргеч бирә, аны дәлилли.

Төрки телле халыкларның, аерым алганда, XX гасырда аларның сәяси һәм мәдәни үткәнен дистәләрчә еллар дәвамында игътибарсыз калдыру, дөнья тарихында әлеге халыкларның роле турында язмау һәм аны аңлы рәвештә киметеп күрсәтү, хәбәрдарлык эрасы башлануга, көчле компенсатор реакция тудырды. Үзенең «Тәгәрмәч метафизикасы: төрки мәдәнигенез тарихы» дигән китабында танылган галим Ф. Урусбиева «Европа традициясендә төрки мәдәният Аристотель заманнарыннан ук, эллиннарныкына капма-каршы куелып, варварларныкы буларак интерпретацияләнде һәм мондый караш, нигездә, Европа материалларына нигезләнде...» дип ассызыклый [Урусбиева, с. 58]. Академик Н. Конрад бу турыда тагын да алданрак искәртә: ул «Урта гасырлар тарихы»нда Көнчыгыш тарихы түгел, ә Европаныкы өйрәнелүне гаделсезлек дип саный [Конрад, с. 103]. Нугайлар – XVII гасырдан соң дәүләтчелеген, территорияләрен югалту, шуннан соңгы бүленү аркасында бөтен бер халыкларны тарихи процесстан чыгару сәясәтеннән аеруча зур зыян күргән халык. Әмма бу халыкның (шул исәптән Россия тарихының иң драматик чорларындагы) роле, бу тема буенча әдәбият шактый күп булып күренүгә карамастан, һаман да тулы кыйммәтле аңлатуга мохтаҗ.

Нугай Урдасы – «Алтын Урда мәдәни традициясенең турыдан-туры варисы» [Оразаев, с. 86], «ләкин Нугай мәдәнияте Урта гасырларга караган документларда бик саран яктыртылган, аның интеллек-

туаль тормышы бөтенләй билгесез булып кала» [Трепавлов, с. 563]. Бу – «нугайлар тарихының тәртипкә салынмаганлыгы» [Фишер, с. 10], «тикшеренүчеләрнең әлеге мәдәнияткә кимсетеп каравы һәм аз хәбәрдарлыгы» [Трепавлов], шулай ук Урта гасырларның гомуми тарихи процессында һәр халыкның ролен ачу мәсьәләсенә игътибар булмау белән дә аңлатыла. Шул ук вакытта Россия халыкларының үткәне турындагы гомуми белемнәр корпусында Нугай сәяси тарихының урыны танылган рус тарихчылары М. Щербатов, Н. Карамзин, С. Соловьев, Л. Гумилев, Г. Миллер, Г. Перетяткович, В. Бартольд һ. б. тарафыннан билгеләнгән [Щербатов, 1903; Карамзин, 1842–1843; Соловьев, 1989; Миллер, 1937; Перетяткович, 1877; Бартольд, 1963].

Тарихи белемнәр – үзенең сәнгати чаралары белән тарихтагы вакыйгаларга һәм драматик борылышларга анализ һәм аңлатма бирүче әдәбиятның нигезе. Иҗаты дәвамында чынбарлыкның катлаулы күренешләрен аналитик тикшерү буенча саллы тәҗрибә, тиешле художество осталыгы туплаган И. Капаев үзенең эсселарында тарихи-мәдәни чынбарлыкны, нугайларның этник нәсел шәҗәрәсен реконструкцияли. Язучының фәнни басмаларга, архив чыганакларына, абруйлы галимнәрнең фикеренә мөрәҗәгать итүе тотрыклы стереотипларны җимерү, уңышсыз гипотезаларны юкка чыгару, үз вакытында аңлы рәвештә барлыкка китерелгән лакуналарны тулыландыру, чынбарлыкны торгызуда аның, нәкъ менә И. Капаевның, авторлык версиясенә укучыны аудару өчен ышанычлы нигез була.

2004 елда И. Капаевның өч кисәктән торган тарихи эссесы – «Үлемсез дала» китабы дөнья күрде. 2008 елда ул Астананың «Аударма» нәшриятында кабат бастырылды. Һәр кисәкнең автоном сюжетлардан гыйбарәт бүлекләре, мөһим мәгълүмати вазифа үтәү белән беррәттән, көчле аналитик башлангыч хисабына, уйлануларга, чагыштыру нигезендә фактларны аңлап җиткерүгә, язучы белән бергә хакыйкать эзләүгә этәрә. Борынгы кешеләрнең теге дөнья турындагы күзаллауларын тасвирлаган меңьеллык Шумер элегияләре, аларда билгеләп үтелгән җирләү ритуаллары һәм мәрхүмнәрне искә алулар нугайларның йөз еллык *кайт, аваз, бозлау* кебек күмү йолаларында очраклы рәвештә генә кабатланамы? («Кургандагы күләгә» бүлеге). Якыннарыңның мәхәббәте, изге гамәлләргә, һәлак булганнарның сугышчан батырлыкларына дан җырлау – Шумер элегияләренең дә, борынгы төрки рун истәлекләренең дә (Күлтәгингә, Билге-каганга, Тоньюкукка багышлаулар), Урта гасырлар нугай героик эпосының да, *йырау* поэзиясенең һәм төрки телле халыкларның күп кенә заманча әдәби жанрларының да (*орнау* – багышлау, *мунълау* – элегия, *алгыс* – изге теләк) нигезе. Бу әсәрләрдә И. Капаевның ачыктан-ачык чагылган автор позициясе структура булдыру функциясен башкара. Евразия һәм Якын Көнчыгыш халыклары арасында уртак дөньяга караш, матди мәдәният нигезләренең, гореф-гадәт, йолаларның якынлыгы, телләрнең лексик составында тәңгәллекләрнең күп булуы,

антропонимнар бердәйлеге, әдәби параллельләрнең булу-булмавы белән расланган мәдәни бәйләнышлар язучы тарафыннан эссеның «Чыгу юлы бар. Керү юлы юк», «Шумерның бөек шаманы», «Тел – тормыш факелы» кебек бүлекләрендә анализлана. Язучы үзенең версияләрен ышанычлы мантыйкка корып нигезли, фәнни, фәнни-популяр, публицистик хезмәтләр авторлары белән сүз көрәштерә, куелган, әмма әле аңлатылмаган актуаль мәсьәләләр буенча аларның позицияләренә үз бәясен бирә. С. Крамерның «Тарих Шумерда башлана», В. Басиловның «Рухлар сайлаган кеше» дигән китаплары турында И. Капаевның сәяси уйланулары, бәяләмәләре, тарихчы галим В. Трепавловның «Нугай Урдасы тарихы» (2001) дип исемләнгән зур тарихи хезмәтенә җентекле анализ ясавы да укучыларны шактый активлаштырып җибәрә. Дәүләт тарихы сәхифәләрендә күренекле шәхесләрнең тарихи портретлары бирелмәүне соңгы хезмәттәге җитешсезлекләрнең берсе дип санап, язучы эссесының берничә бүлеген шуларга багышлый. Алар –Урта гасырларда бөек Евразия дәүләтен төзегән Чыңгызхан («Аңа уңыш юлдаш булды» бүлеге), Нугай Урдасы гаскәр-дәүләтен төзегән Идегәй һәм *шәҗәрә* – бөек кенәзләрнең нәсел шәҗәрәләре («Үткәннәргә хөрмәт күрсәтү һәм киләчәкне бүләкләү» бүлеге), этнонимнарның барлыкка килүе турында версияләр, тел параллельләре (кыпчакларның «Игорь полкы турында җыр»ны укуы») һ.б. Автор фикерләвенең афоризмнарга бай булуы, күптармаклы сюжет системасын һәм фактларның үзара нәтиҗә-сәбәп бәйләнешен төзү мантыйгы фәлсәфи концепциягә, зиһенгә алына торган тарихи вакыт чынбарлыгына туры килә.

Гасырлар чигендә, иң яңа чорда эссе И. Капаев иҗатында ныклап тамыр җәя. Аның әсәрләренең фәнни-тикшеренү юнәлешендә булуы нугай гуманитар фәне, барыннан да элек, тарих, филология үсешенә зур импульс бирә. Милли бердәмлек мәсьәләләренең әһәмияте, үткәннәрдән гыйбрәт алу, халыкның бүгенге чынбарлыгыннан чыгып, киләчәккә омтылышлы булу – болар барысы да уйланучан язучы әсәрләренең нигезендә ятарга тиеш.

И. Капаевның тарихи-мәдәни хәтерне соң дәрәҗәдә дөрес итеп реконструкцияләүгә хезмәт итүче материалны актив эзләү һәм фикерләү юнәлешендә эшләү ниятен раслап, 2012 елда Мәскәүдә аның «Нугай мифлары, легендалар һәм ышанулар» (Мифологик сүзлек тәҗрибәсеннән) дигән күләмле һәм әһәмиятле хезмәте дөнья күрә. Бу басманың мәгълүматка бай һәм дәлилле булуы белән аерылып торган, фольклор материалы белән иллюстрацияләнгән сүзлек мәкаләләре эссе жанрында да бәян ителгән. Хезмәтнең кыйммәте нугай гуманитар фәне – лингвистика, этнология, фольклористика, әдәбият белеме, культурология үсешенә зур өлеш булып кергән универсаль үзгә материалны теркәп калдыруда. Бу – әлеге фән тармаклары өчен нигез материал, халыкның (юклыкта эреп югалудан сакланып калган) күпгасырлык яшәеше турында оригиналь гыйлем, этносның менталитетен чишү, дөньяны аңлавын төшенү ачкычы. Әлбәттә, бу материал,

рухияткә кызыксыну уяту максатында, мөмкин булган барлык чаралар белән мәдәни киңлектә популярлаштырылырга тиеш.

2014 елда Мәскәүнең «Голос-Пресс» нәшриятында И. Капаевның нугай телендә язылган 4 томлык сайланма әсәрләренең өченче томы нәшер ителә, анда язучының соңгы елларда иҗат ителгән сәяхәт жанрында язылган тарихи эссесы «Ялын янлы Сарайшык» басыла. Әсәрдә Урта гасырлар Нугай Урдасы башкаласының тарихы нугай әдәбиятында күләмле әсәрдә беренче тапкыр сәнгати мәгънәгә төреп яктыртыла һәм хәзерге Көнбатыш Казакъстан территориясендә бүгенге нугайларның тарихи һәм мәдәни хәтере символы турында хиссият дәрәҗәсе һәм фактларга байлыгы ягыннан үзәкләргә үтеп керерлек ышанычлы кыйссага әверелә. Ул шул ягы белән кыйммәтле дә.

Казакъ галимнәре И. Тасмагамбәтов һәм З. Самашевның «Сарайчык» дип исемләнгән рәсемле фәнни басмасында Нугай Урдасының төп шәһәре «Европа һәм Азия чигендә стратегик яктан иң әһәмиятле урында төзелгән, Европа илләреннән һәм Идел буенда Алтын Урда башкаласыннан (Сарай-Бату һәм Сарай-Бәркә), Харәзем, Иран, Һиндстан һәм Кытайдан килүче трансконтиненталь кәрван юлының бер өлешендә куркынычсызлык тәэмин итүче» шәһәр буларак характерлана [Тасмагамбетов, Самашев]. Шунда ук авторлар Сарайчыкта зиннәтле сарайлар, кәрвансарайлар, мунчалар, мәчет-мәдрәсәләр төзелүе турында язалар. Аларны шактый билгеле архитектура мәктәпләреннән чыккан талантлы осталар торгыза. Сарайчык халкы гыйлемле булуы белән аерылып тора. Савыт-сабалардагы, бронзадан эшләнгән әйберләрдәге, шулай ук кәгазьдә теркәлгән төрле язулар да шул хакта сөйли». Ул һөнәрчелек нык үскән шәһәр була, тимерчеләр, чүлмәкчеләр, бронза коючылар, пыяла өрүчеләр, зәркәнчеләр, тукучылар эшләнмәләренең сакланган калдыклары да шуны раслый. Сарайчык турында истәлекләр калдырган күпсанлы сәяхәтчеләр дә шул турыда язганнар.

И. Капаевның классик Көнчыгыш *сапар-нам*ә стилендә язылган «Ялын янлы Сарайшык» әсәре – лирик геройның элеккеге бөек дөньяга Ставрополь далаларыннан алып Казакъстан киңлекләренә кадәр җәелгән мәйданда гына түгел, ә вакытта, тарихта нугайларның күпгасырлык мәдәнияте, гореф-гадәтләре, риваятьләре, истәлекләре дөньясына да сәяхәте. Бу –халыкның бүгенге көне турында уйланулар да.

Әсәргә кертелгән мәгълүматның энциклопедик характерда булуы – Ставрополь төбәгендәге киң халыкка билгеле булмаган хәзерге нугай авыллары, сулыклар турында тарихи белемнәр, Әстерхан һәм Атырау өлкәләре далаларының ландшафт тасвирламалары, Бөек Ефәк юлы шәһәрләре тарихы, Казакъстан җитәкчелеге карары белән күптән түгел генә төзелгән тарихи Сарайчык, Бөек хакимнәр пантеоны, һәр бөек кешенең язмышы – сәяхәтченең бәянын да, укучыны да баета.

Әсәрнең тарихчы галим тарафыннан нигезле оештырылган материалы, эмоциональлеге, чынбарлык картиналарының Урта гасырларның гөрләп чәчәк атучы Сарайчыгы тарихыннан ирреаль күзаллаулар белән алышынып торуы, вакыт-вакыт геройны биләп алган

фәлсәфи уйлануларның еш кына өзелүе аркасында, бәянны эссе кебек сыгылмалы һәм күләмле жанр законнарына буйсындыра. Автор-хикәяләүченең фаҗига тулы, төп тезисын этносның яшәүгә сәләте тәшкил иткән сөйләме йөрәкне кузгата, дулкынландыра, чөнки мондый оптимизм өчен таяныч эзләгәндә, гасырлар дәвамында нугайларга сугышчан дан китергән бөек сугышчы-хакимнәрнең исемнәре санала. Алар халык хәтерендә яшәгәндә, халык та яши.

«Ялын янлы Сарайшык» – жанр ягыннан эссе-метафора. Көчле хакимнәрнең коточкыч ызгыш-талашлары белән, ә хәзер вакыт тарафыннан да җимерелгән шәһәр – И. Капаев әсәрендә ут һәм кылыч, халыкны, туган йортны сакламау сәясәтләренең нигезсезлеген күрсәткән символ буларак тәкъдим ителә. З. Самашев болай дип яза: «Хәзерге вакытта фарватерын алыштырган Җаек елгасы сулары астында шәһәрлек бик тиз юкка чыгып бара. Көчле һәм тиз су агымы, яр буенда кеше скелетлары, кирпечләр, керамик савытлар һәм башка көнкүреш әйберләре генә калдырып, борынгы шәһәр катламнарын юа».

И. Капаев та түбәндәге юлларны укыйбыз: «Мин кайчандыр ата-бабаларым ташлап киткән шәһәрне артта калдырам. Әмма минем хәтеремдә бу хәрабәләр түгел, ә хыялымда туган Сарайчыгым образы кала. Һәм ул, минем шәһәрем образы, дөньядагы иң мөһим вакыйгаларны да күләгәдә калдырырга сәләтле. Мин дәшмим һәм минем юлдашларым да дәшми...»

2017 елда Мәскәүнең «Голос-Пресс» нәшрияты И. Капаевның «Язмыш кылычы» дигән тагын бер китабын чыгарды. Дәрәҗәле яңа басманың жанрын автор үзе тарихи тикшеренүләр дип билгеләнгән. Бу чыннан да шулай. Китапның беренче өлеше – авторның «Чыңгызханнан алып Идегәйгә кадәр» дип аталган эссесының тулыландырылган һәм эшкәртелгән варианты. Бөек тарихи шәхесләрнең (Чыңгыз хан, Тамерлан, Туктамыш, Идегәй) тарихтагы, аерым алганда, Алтын Урда, Нугай Урдасы тарихындагы роленә карашын И. Капаев әлеге тема буенча тупланган зур фәнни әдәбиятны полемик анализлау барышында белдерә. Әлеге проблема буенча калыплашкан стереотиплардан аерылып торган үз фикерен ассызыкларга да онытмый.

Шул ук исемдәге китапның икенче өлеше «Кече Нугай Урдасы тарихын өйрәнү» дигән өстәмә исем белән дөнья күрә. Зур Нугай Урдасы таркалганнан соң көчәя барган әлеге сәяси бергәлек тарихы буенча фәнни публикацияләр исемлеге гаять бай. Әмма геосәяси планда XVI–XVII гасырларда (төбәк дәрәҗәсендә генә түгел) Кече Урданың роле турында ачыкланмаган сораулар кимемәде. Моның сәбәбе, мөгаен, берничә мөһим факторның тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калуындадыр, ә объектив тарихи картина тудыру өчен, аларны һичшиксез исәпкә алырга кирәк. И. Капаевның «Язмыш кылычы» фәнни тикшеренү форматында гына кала алмый, чөнки Россия, Госманлы империясе, Алтын Урдадан соң оешкан берничә дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы борылышларын ачканда, автор нәкъ менә Кече Урда тарихына таянып эш итә.

XVI гасыр уртасыннан XVII гасыр уртасына кадәрге чама белән бер гасырлык вакыт аралыгында булган вакыйгаларны анализлау нугайлар тарихында, аерым алганда, Россия дәүләте өчен бөек тарихи альтернативалар чоры контекстында тормышка ашырыла. Россия өчен бу – XVII гасыр башындагы «Фетнәле заман» («Мәскәү фетнәсе һәм безнең фетнә» бүлеге). Автор Иван Грозный, ике Ялган Дмитрий, Василий Шуйский идарә иткән чорларда һәм нугай, һәм рус тарихына караган күренекле шәхесләрнең (Симеон Бекбулатович; чын исеме Сәин Бикбулат), Петр Урусов; чын исеме Орак Урыс), Кантемир һ.б.) роле турындагы мәгълүматларны актуальләштерә. Хәзерге Россия үзен күпмилләтле дәүләт буларак таныту сәбәпле (өстәвенә ул баштан ук шундый булып оеша), әлеге тезисны нигезләгән фактларны актуальләштерү, ил халыкларының Россия дәүләтчелеген торгызуга керткән өлешен ачу аның ныгуына гына хезмәт итәчәк. И. Капаевның эссесында башка таныкламалар да, шул исәптән нугайлар фольклорында чагылдырылганнары да җитәрлек, бу укучылар өчен бөек дәүләтләр оешу процессларының катлаулы, каршылыклы характерын мавыктыргыч итеп ачарга мөмкинлек бирә. Һичшиксез, И. Капаевның «Язмыш кылычы» махсус өйрәнелергә тиеш, чөнки әсәрнең бик бай эчтәлекле, форма ягыннан үзенчәлекле булуы, бәян итүче авторның аерым роле һ. б. шуны таләп итә.

Тарих һәм хәзерге заман – Иса Капаевның иң яңа эссе прозасындагы әлеге ике куәтле полюс өзлексез философия симбиозын тудыра, мондый кырда язучы иксез-чиксез продуктив, нәтиҗәле, һәм иҗади потенциалга ия.

**Әдәбият**

*Бартольд В.* История культурной жизни Туркестана. Соч. М., 1963.

*Карамзин Н.* История государства Российского. СПб., 1842–1843.

*Конрад Н.И.* Средние века в исторической науке // Конрад Н.И. Запад и Восток. М. 1966. 496 с.

*Миллер Г.* История Сибири. М.-Л., 1937.

*Оразаев Г. М.* Памятники тюркоязычной деловой переписки в Дагестане 18 века. Махачкала. 2002. 382 с.

*Перетяткович Г.* Поволжье в 15 и 16 вв. М. 1877.

*Соловьев С.* История России с древнейших времен. М., 1989.

*Тасмагамбетов И., Самашев З.* Сарайчик. Алматы. 2001. 320 с.

*Трепавлов В.В.* История Ногайской Орды. М.: Восточная литература. 2001. 752 с.

*Урусбиева Ф.А.* Метафизика колеса. Вопросы тюркского культурогенеза. Сергиев Посад. 2004. 207 с.

*Фишер И.Э.* Сибирская история с самого открытия Сибири до завоевания сей земли российским оружием. СПб., 1774. Цит. по указ. работе В.В. Трепавлова.

*Щербатов М.* История Российская от древнейших времен. СПб., 1903;

***Суюнова Насипхан Хусин кызы,***
*филология фәннәре докторы, У.Д. Алиев исемендәге*
*Карачай-Черкас дәүләт университетының*
*карачай-балкар һәм нугай филологиясе кафедрасы профессоры*